ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

03.11.2023 г. Казань № 353-22/кс-2023

2024-2028 елларга «Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 03.11.2023 № 46-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Никос и Мария» фирмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «Никос и Мария» фирмасы» ЖЧЖ) өчен әлеге карарга 1 нче кушымта буенча эчәргә яраклы суга календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2024 елның 1 гыйнварыннан 2028 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә, салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Никос и Мария» фирмасы» ЖЧЖ өчен эчәргә яраклы суга 2024 – 2028 елларга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрларын билгеләргә.

4. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Никос и Мария» фирмасы» ЖЧЖ Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы

карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.11.2023 № 353-22/кс-2023
карарына 1 кушымта

2024-2028 елларга салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Никос и Мария» фирмасы» ҖЧҖ
өчен эчәргә яраклы суга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Ел | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|---|
| | «Казан шәһәре» муниципаль берәмлеге | | |
| 1 | «Никос и Мария» фирмасы» ҖЧҖ* | 01.01.2024 башлап 30.06.2024 кадәр | 56,23 |
| | | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр | 68,99 |
| | | 01.01.2025 башлап 30.06.2025 кадәр | 65,35 |
| | | 01.07.2025 башлап 31.12.2025 кадәр | 65,35 |
| | | 01.01.2026 башлап 30.06.2026 кадәр | 65,35 |
| | | 01.07.2026 башлап 31.12.2026 кадәр | 70,57 |
| | | 01.01.2027 башлап 30.06.2027 кадәр | 70,53 |
| | | 01.07.2027 башлап 31.12.2027 кадәр | 70,53 |
| | | 01.01.2028 башлап 30.06.2028 кадәр | 70,53 |
| | | 01.07.2028 башлап 31.12.2028 кадәр | 76,06 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф карарларын кабул
итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү
бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
03.11.2023 № 353-22/кс-2023
карарына 2 кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Никос и Мария» фирмасы» ҖЧҖ өчен 2024 – 2028 елларга эчә торган суга тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| т/с | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | Су югалту дәрәҗәсе | Электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
| | | | мең сум | % | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Никос и Мария» фирмасы» ҖЧҖ | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2024 | 1 804,45 | х | - | 7,85 | 2,38 |
| | | 2025 | х | 1 | - | 7,85 | 2,38 |
| | | 2026 | х | 1 | - | 7,85 | 2,38 |
| | | 2027 | х | 1 | - | 7,85 | 2,38 |
| | | 2028 | х | 1 | - | 7,85 | 2,38 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге